| | | |
|---|---|---|
| **ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**<br>**РЫБНО-СЛОБОДСКОГО**<br>**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**<br>**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**<br>**БАЛЫК БИСТӘСЕ**<br>**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ**<br>**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

09.11.2018 Балык Бистәсе штп. № 258пи

Татарстан Республикасының Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә урнашкан кешеләр күпләп була торган урыннар исемлеген раслау турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Сәүдә объектларының (территорияләренең) террорчылыкка каршы саклануына һәм сәүдә объектының (территориясе) куркынычсызлык паспорты формасына таләпләрне раслау турында" 2017 елның октябрендәге № 1273 карары басылу белән бәйле рәвештә һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә, сәүдә объектларында (территорияләрдә) күпләп тору урыннары исемлегеннән төшереп калдыру зарурлыгынан һәм » "Террорчылыкка каршы көрәш турында"2006 елның 6 мартындагы 35-ФЗ номерлы федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 1 өлешенең 6.1 пункты, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе Милли гвардиясе гаскәрләре тарафыннан мәҗбүри сакланырга тиешле кешеләр һәм объектлар (территорияләр) массакүләм тору урыннарының террорчылыкка каршы сакланышына таләпләрне һәм мондый урыннарның куркынычсызлык паспортлары формаларын раслау турында» 2015 елның 25 мартындагы 272 номерлы карары Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставына туры китереп карар бирәм:

1.Татарстан Республикасының Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә урнашкан кешеләр күпләп була торган урыннар исемлеген расларга.

2. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә урнашкан кешеләр күпләп була торган урыннар исемлеген раслау турында»2017 елның 14 декабрендәге 264пи номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. . Әлеге карарны http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының

хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үз өстемдә калдырам.

Җитәкче Р.Л. Исланов

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
районы Башкарма
комитетының
2018 елның 9 иоябрендәге
258 пи номерлы карары
белән расланган

**Татарстан Республикасының Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә урнашкан кешеләр күпләп була торган урыннар исемлеге**

| № п/п | Кешеләр күпләп була торган урынның атамасы | Кешеләр күпләп була торган урын адресы | Кешеләр күпләп була торган урын категориясе |
|---|---|---|---|
| 1 | Балык Бистәсе муниципаль районы Советы һәм Башкарма комитеты бинасы | 422650, Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, штп.Балык бистәсе, Ленин ур., 48 | 3 |
| 2 | Балык Бистәсе муниципаль районы Советы һәм Башкарма комитеты, Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе, Татарстан Республикасының «Балык Бистәсе районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» ДКУ бинасы | 422650, Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, штп.Балык бистәсе, Ленин ур., 48А | 3 |
| 3 | Үзәк базарның административ бинасы | 422650, Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, штп.Балык бистәсе, З. Шәймәрданов ур., 73А | 2 |
| 4 | "Чингисхан»офис-сәүдә үзәге бинасы | 422650, Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, штп.Балык бистәсе, З. Шәймәрданов ур., 81Б | 3 |
| 5 | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе районының | 422643, Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе | 3 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | Анатыш авылы Богоявленский чиркәве мәхәлләсе бинасы (Мәскәү патриархаты) | муниципаль районы,Анатыш ав., Үзәк ур., 37. | |
| 6 | Балык Бистәсе шәһәр тибындагы бистәнең Үзәк мәчете бинасы | 422650, Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, штп.Балык бистәсе, Совет ур., 91 | 3 |
| 7 | Иҗтимагый әһәмиятле мәсьәләләр турында күмәк фикер алышу һәм җәмәгатьчелек фикерләрен белдерү өчен, шулай ук иҗтимагый-сәяси характердагы актуаль проблемалар буенча җәмәгатьчелек фикерен гавами белдерү өчен махсус билгеләнгән яисә җайлаштырылган урын Балык Бистәсе ш. т. б. Набережная ур. | 422650, Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, штп.Балык бистәсе, Яр буе ур., | 1 |
| 8 | Бәйрәм чараларын үткәрү өчен махсус билгеләнгән урын («Мәйдан») Балык Бистәсе ш. т. б. Новая урамы (татар халык бәйрәме Сабантуй үткәрү территориясе) | 422650, Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, штп.Балык бистәсе, Яңа ур. | 1 |